**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**Заключительный этап**
**ОТВЕТЫ**
**2024-2025 учебный год**

**11 класс**

**I. Татар телендә *агач тамыры* һәм *нәсел тамыры* сүзтезмәләре кулланыла. Әлеге сүзтезмәләрдәге *тамыр* сүзендә нинди аерма бар? Тел белемендә бу күренеш ничек дип атала? Җавабыгызны дәлилләгез**. / В татарском языке употребляются словосочетания *агач тамыры* и *нәсел тамыры*. Чем отличается в данных словосочетаниях слово *тамыр*? Как называется данное лингвистическое явление? Обоснуйте свой ответ. **(***15 баллов. За верное толкование и объяснение значениия каждого словосочетания по 5 баллов; за определение термина – 5 б.***)**

**Агач тамыры** – агачның җир астындагы тармакланып торган өлеше.
**Нәсел тамыры** - кешенең ата-бабасы, чыгышы, нәсел-ыруы.
Тамыр – күпмәгънәле сүз
Бу - күпмәгънәлелек /полисемия күренеше.

**II. Сүзләрнең сүз ясалыш чылбырын языгыз. Һәр чылбыр ахырында түбәндә бирелгән сүзләр булсын**. / Запишите словообразовательные цепи, в конце которых стоят предложенные ниже слова. **(10 баллов.** *За каждый правильный вариант по 5 б.).*

*Эшмәкәрлек, тузанлы*
**эш – эшмәкәр – эшмәкәрлек.**
**туз – тузан - тузанлы**

**III. Сүзләрнең татарча тәрҗемәсен языгыз**. / Переведите слова на татарский язык (**10 баллов**. *За каждый правильный вариант по 1 баллу* ).

*Политика - сәясәт*
*Ландыш – энҗе чәчәк*
*Факт – дәлил*
*Мастерская – остаханә*
*Бабочка- күбәләк*
*Экономика – икътисад*
*Справедливый – гадел*
*Врач – табиб*

*Молодость-яшьлек*
*Темнота - караңгылык*

**IV. Хәреф хаталарын табып, асларына сызыгыз.** / Найдите орфографические ошибки и подчеркните их **(16 баллов).** *За каждый правильный ответ по 2 балла*).

Җәй узенең соңгы чәчкәләрен коеп утырган моңсу вакыт иде. Агачларда сары яфраклар күреңгәли башлады. Әммә йомшак җылы бар әле. Иртән мул булып салкын чык төшә, үлән тәлгәшләренә бәллүр алкалар булып эленә. Җәй буе бик еш яуган яңгырлар туктады, кояшлы көннәр китте. Җәй көзгә таба авыша башлаганда, шулай якты хавада, җирдә пәревез җепселләре елык-елык килеп уйнаган чаклар булып ала... Көпчәк эзендәге туфрак нәкь көл төсле, шактый калын, шуңа күрә ком иңеп, батып керә дә барырга комачаулый иде. (*Х. Камал*)

**V. Төшеп калган сүзләрне языгыз** / Впишите пропущенные слова **(10 баллов**. *За каждый правильный ответ по 2 балла.)*

1. Татар телендә УНИКЕ сузык фонема бар. 2. Сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә торган фән ЭТИМОЛОГИЯ дип атала. 3. Сүзнең төп лексик мәгънәсен белдерә торган кисәк ТАМЫР дип атала. 4. *Авылның урамы, китапның бите, көннәрнең берендә* сүзтезмәләрендә беренче сүз ИЯЛЕК килешендә килгән. 5. Баш кисәкләрдән генә торган җөмлә ҖЫЙНАК ҖӨМЛӘ дип атала.

**VI. Җөмләгә 1) синтаксик анализ ясагыз, 2) аның схемасын сызыгыз һәм 3) төрен билгеләгез. Җөмләдәге сүзләргә морфологик анализ ясагыз. /** Сделайте 1) синтаксический разбор предложения, 2) укажите схему и 3) определите тип предложения Сделайте морфологический разбор выделенных слов в предложении (**25 баллов**. *За каждое задание по синтаксическому разбору по 5 баллов. За каждый правильный ответ по морфологическому разбору по 2 балла.)*

1) ***Бөркетләр яңгырдан тәмам чыланган***, *2)* ***каурыйлары*** *асылып-асылынып төшкән. (Ф. Яхин)*

Бөркетләр - ия, яңгырдан – сәбәп хәле, тәмам – күләм хәле, чыланган – хәбәр, каурыйлары – ия, асылып-асылынып – рәвеш хәле төшкән – хәбәр.

[1.] = [2.]

Санау интонациясе

Бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә

***Бөркетләр*** - тамыр, урт. исем, баш килештә, күплек санда
***яңгырдан*** - тамыр, урт. исем, чыгыш килешендә, берлек санда
***тәмам* –** тамыр**,** күләм-чама рәвеше
***чыланган*** - тамыр фигыль, билгесез заман хикәя фигыль, 3 зат, берлек сан, барлыкта
***каурыйлары*** - тамыр, урт. исем, баш килештә, күплек санда, 3 зат тартым белән төрләнгән

**VII.** ***Агач – җимеше белән, кеше – эше белән*** **мәкален сез ничек аңлыйсыз? Шушы мәкальдә әйтелгән үз мөнәсәбәтегезне 80 сүздән ким булмаган язмада белдерегез. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез./** Как вы понимаете пословицу *Дерево известно своей плодовитостью, человек своими великими делами*? Опираясь на это **выражение,** напишите сочинение-рассуждение (не менее 80 слов). Выражая свое отношение приведите не менее 2 довода-примера ***(14 баллов)***.

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеге гомуми. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил дә юк | 1 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | **ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 2 |
| | 2-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 2 |
| | 2-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **14** |